
Балалар журналы

Салават күпере

ISSN 0868-4545

Песнәк бага тәрәзәгә –
Очып килгән бүген дә...
...Җәй бүләге алма ята
Өйдә – тәрәз төбендә.



Игътибар! Яңа бәйге!
Беренче урынны алучыга – компьютер!

Куяннар – агач башында...

Борын-борын заманда, әле син дә, «Салават күпере» журналы да булмаган заманда яшәгән ди... Әйе, әйе, кара урманда бик күп киек-җәнлекләр, кош-кортлар яшәгән ди. Бу урманда бары аю гына булмаган ди.

Куяннар ул вакытта агач башында яшәгән. Урман кошларының оялары җирдә – агач төпләрендә булган. Төлкеләр ботакта кунган. Керпеләр җир астында гомер кичергән ди.

Боларны Ходай Тәгалә шулай яраткан. Барысының үз туган теле булган, шул телдә аңлашканнар, сөйләшкәннәр ди. Куяннар, куян телендә аңлашкан, кошлар үз телләрендә җырлаган, хәтта төлке дә үз телендә хәйләле икән ди.

Барысы да бик бәхетле булган, һәммәсе дә рәхәт яшәгән ди. Үзенең туган телендә сөйләшкәч, әлбәттә, бәхетле булалар инде.

Менә берзаман бу урманга бик усал, дәһшәтле Әппәс исемле аю килеп чыккан. Аю Әппәс берсенең дә телен аңламаган, бер җәнлек белән дә аралашып, сөйләшеп китә алмый икән ди теге. Аю Әппәснең моңа бик нык ачуы килгән һәм ул каты итеп үкереп җибәргән: «Моннан соң мин аңламаган телдә сөйләшмәгез! Бар кош-корт та, киек-җәнлекләр дә бүгеннән башлап минем телемдә генә сөйләшергә тиеш. Аю Әппәс теле иң матур тел, минем телем иң әйбәт тел!» – дип боерган ул.

Аю Әппәстән куркып бар урман халкы дер калтыраган. Куяннар куркуларыннан шундук, үз телләрен ташлап, Аю Әппәс телен өйрәнергә керешкән, хәтта төлкеләр дә бу боерыкка бирешкән. Урман кошларының гына Аю Әппәскә



буйсынасылары килмәгән. Алар һаман үз телләрендә җырлыйлар икән ди.

Кошларның бу батырлыгы Ходай Тәгаләгә бик ошаган. Ул аларга канат биреп, агач башына меңгергән. Куркак куяннар җиргә төшкән. Алар артыннан төлкеләр дә. Хәтта бүреләр дә Аю Әппәскә охшатып уларга тырыша икән.

Бу әкият әле моның белән генә тәмамланмаган.

Укучым!

Син хәзер шушы урыннан әкиятне үзең дәвам итәргә тырыш. «Салават күпере» тырыш балаларны бик ярата һәм аларга бүләкләр дә бирә.

Әкиятне үзеңчә дәвам ит һәм җиңеп чык!

Беренче урынга – компьютер.
Икенче урынга – велосипед.
Өченче урынга – видеоплейер.



Рәссам Светлана ПРИВИНА

Конкурска йомгак бу елның сентябрь аенда ясалачак. Журналыбызның сентябрь санында бәйгедә җиңүчеләрнең исемнәре аталачак.

«Салават күпере».





Рафис Корбан

шигырьләре




Кунаклар

Дәштем бүген кунаклар.
Кунакларым – курчаклар.
Табын кордым мул итеп,
Куйдым чәен, кәнфитен.

Берни ашамадылар.
Кабып та бакмадылар.
Әллә теләмәделәр,
Әллә яратмадылар.

Сыйласам да никадәр,
Утырдылар тик кенә.
Ашамагач, кунакка
Килгәннәрдер ник кенә?









Автомат

Әти миңа туган көнгә
Бүләк итте автомат.
– Син хәзер чын солдат, – диде,–
– Автоматтан ат та ат!

Әйбәт атты автоматым.
Ике көн буе аттым.
Курыкмагыз атар бу дип,
Мин инде аны ваттым.



-чык - чык чырык
чык - чырык!

Чыпчык

Һаман чыркылдый бер чыпчык:
– Чык-чык чырык та, чык-чырык!
Сорадым шунда чыпчыктан:
– Шул да булдымы җырың?

Әйтте чыпчык:
– Бик теләсәм,
Сайрыйм матур итеп тә.
Тик куркам мин – ул чагында
Тотарлар дип читлектә.

Рәссам Алла АЙСИНА

Песи битен юа

Ашап туйгач, безнең песи,
Аңлый алмыйм ни эшләп,
Битен юа, тәпиләрен
Теле белән юешләп.

Песи әллә белми микән
Су чистарак юганын?
Юар иде, юынгычка
Буе җитми шул аның.





Кунак

«Тук-тук-тук!» та «тук-тук-тук!» дип,
Кем әле тәрәз чиртә?
Татлы йокыдан уятып,
Кем йөри шулай иртә?

Сары түшле нәни песнәк
Кунган тәрәз төбенә:
Җим сорап дәшә икән бит
Ул миңа үз телендә!

Тәрәз ачып, җимнәр сибәм,
Алларына су куям.
Күрче, ничек куана ул, –
Нәкъ шаян кызчык сыман!

Чүпли тары бөртекләрен,
Барсын да күреп ала.
Сикергәли, канат җилпи,
Үзенчә аваз сала.

Сыйлангач, кошчыгым тагын,
Шаяртып, «тук-тук» итә.
Монысын инде, рәхмәт әйтеп,
Яратып кына чиртә.

Римма ШӘЕХОВА, 14 яшь.
Азнакай.

Кышкы уен

Чаңгы шуып йөрибез дә
Кар атышып уйныйбыз.
Хәлдән таеп бетсәк тә, без
Уеннан һич туймыйбыз.
Уеннан һич туймасак та,
Өйгә кермичә булмый,
Чөнки безнең өчен беркем
Дәрес әзерләп куймый.

Гүзәл ГАЛИМУЛЛИНА, 10 яшь.
Кукмара, 2 нче мәктәп.



Алия ЮНЫСОВА, 9 яшь.
Сарман, Сарсаз Тәкермән.



Эльвина ӘХТӘМӘНОВА, 7 яшь.
Кукмара, Ташлы Елга.



Лилия ФӘЛӘХОВА, 11 яшь. Мамадыш, Шәдче.

Өзелә язды өмет...

Кышны көтә-көтә быел
Өзелә язды өмет...
Буран белән, дулый-дулый,
Чыкты бит бер көн килеп!

Каплады йөрер юлларны
Ак-мамык карлар белән!
Шул матур кар-җепләрдән ул
Түшәде йомшак келәм.

Динара ЯРУЛЛИНА, 8 яшь.
Теләче, Олы Мишә.



Әдилә ХАННАНОВА, 8 яшь. Азнакай, Сәпәй.



Ләйсән ХӘБИРОВА, 11 яшь. Баулы.



Галимҗан ГЫЙЛЬМАН

Әйбәт ялган

(Хикәя)



Быел кыш сәер булды. Кары да аз яуды, суыгы да ялындырып кына йөрде. Мартка керәм дип торганда чын кыш килде – берничә көн эчендә бөтен дөнья акка чумды, суыкның да бит очларын чеметеп ала торганы иде.

Мәктәптән кайтып озак юанмады Булат, бакчага кар белән уйнарга чыкты. Әйе, кар белән дә уйнап була. Аны башта сибеп-чөеп уйныйсың, аннары көрт таулары өеп, эченә куыш ясыйсың, иң ахырдан, ап-ак кар өстендә ауный-ауный хәл җыясың. Шулай кар түшәк өстендә күккә карап ятканда Булатның күзенә ике кызгылт шар йомарламы чалынды. Кар сарган алмагачның иң югары ботакларында эленеп торалар иде бу матур шарлар.

Булат үзенең ачышыннан елмаеп җибәрде: «Алмалар бит болар! Көздән калган алмалар!» Сикереп торды, якынрак барды, үрелеп карады. Алмалар, кыймылдап, үзләренең җанлы, тере икәнлекләрен сиздереп куйдылар. Булатның алма дигәннәре чынлап та тере булып чыкты: алар алма да түгел, чып-чын кызылтүшләр икән! Шундый өшегәннәр, туңганнар, мескенкәйләр, кузгалырга да куркып утыралар...

Булат бик кызганды аларны. Кесәсе төбендә җыелган печенье, прәннек валчыгын кар өстенә сибәргә кереште. Кошлар аның бу изгелегенә игътибар итмәделәр, уенчык кошлар кебек балкып, әмма туңып-катып утыра бирделәр. Аларга карап торып, Булат үзе дә өши башлады. Кешеләргә җайлы – өшесәләр, өйләренә керәләр дә китәләр. Кошларның өйләре юк шул – алар көннәр буе үзләренең ботакларында өшеп утыралар...

Кызылтүшләр дә, өшеп-туңып, алмагачта утырып калдылар, Булат йөгереп өенә кереп китте.

Чишендергәндә әнисе малаеның кесәләрен капшый башлады. Әнисенең йөзенә карап, Булат ниндидер борчу барлыгын аңлады.

– Улым, кая китте синең бер бияләең?

– Шундадыр...

– Кайда? Менә – берсе генә бит...

Булат үзен тыныч тотты. Нигә борчылырга? Бакчада, уйнаган җирдә калгандыр...

Бияләй, чынлап та, кызылтүшләргә җим сибеп торган урында ята иде. Булат аны үрелеп алмакчы булды, шулвакыт бияләй селкенеп куйды. Җанлы әйбер диярсең... Ул чынлап та җанлы булып чыкты. Аның җаны – эчендәге кызылтүш иде. Булат, хәтәр суыктан качып, йомшак йоннан бәйләнгән бияләй эченә килеп кергән кызылтүшкә озак кына карап торды. Чыкмасмы? Юк, җылы бияләй эчендә оеп утырган песнәк чыгарга уйламады да. Ул арада каяндыр икенче кош очып төште. Анысы да, нидер өмет иткән кебек, башын әле бер якка, әле икенче якка янтайтып, өзгәләнеп, Булатка карап тора башлады.

Булат аңа нәрсә кирәген аңлады. Бу кызылтүшкә дә җылы кирәк, ә җылы.... җылы бияләй эчендә яши...

Булат кергәндә әнисе мичтән тәгәрәтелгән бәрәңге алып тора иде.

– Таптыңмы?

– Юк, әнием, тапмадым. Мин аны мәктәптә калдырганмын, ахры. Иртәгә эзләп табармын, яме?..

– Барганда өшемәсме соң кулларың?

– Юк, әнием, өшемәс, минем кесә җылы...

– Ярый, улым, үзең беләсең. Син бит хәзер үскән инде!

Булат алай ук иркә малай түгел. Әмма әнисе башыннан сыйпап алса, үлә дә китә. Бу юлы да шулай булды, кәефе килеп, шундук кичә укый башлаган китабына барып ябышты, әнисенең, үзалдына елмаеп, тәрәзә аша бакча ягына карап-карап алуын да сизмәде...



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Мин бит бу?!



– Кем – биюче, кем – җырчы,
Кемнәрдер – җил куучы...
Мин дә инде бүгеннән үк –
Фигуралы шуучы!

Әтнә, Иске Җогып.


Адилә, 6 яшь


Алия, 3 яшь

– «Япон тактасы» диләр дә...
Японныкы түгел шул!
Татар көйләрен сыздырам:
«Идел бит ул, киң бит ул...»

Әлмәт, Сөләй.



Диләрә, 3 яшь

– Мисырда булган чагым
Әле дә истә минем:
Фиргавен белән бергә
Сурәткә төшкән идем...

Бөгелмә, Иркен.


Салават, 4 яшь

– Мин бик уңган (мактанмыймын!):
Аш пешерәм, кер юам...
Кирәк икән, һич иренмим,
Пилмән дә ясап куям!

Балык Бистәсе.


Инсаф, 6 яшь


– Эшләпәсе берни түгел,
Карагыз сез күгенә:
Салават күпере юллыйм
«Салават күпере»нә!

Аксубай, Яңа Үзи.


Инзилә, 1 яшь 2 ай

– Дога укыйм, тәсбих тартам,
Әле нәни булсам да...
Сурәтемне сезгә юллыйм –
Бастырырсыз бу санда!

Саба, Пүкәл.


Гадилә, 4 яшь
Марат, 3 яшь

– Күңелләрем иләсләнә,
Күргәч синең йөзеңне:
Чит-ят күзләр күргәнче, дим,
Үбим әле үзеңне!

Балык Бистәсе, Котлы Бөкәш.



Булатның туган көне

Бүген Булатның туган көне. Ул бәйрәм табынына дусларын җыйды. Дуслары аңа төрле бүләкләр алып килгән иде.

Балалар җырладылар, биеделәр, кызыклы уеннар уйнадылар. Уйнаган чакта, билгеле инде, өйнең асты-өскә килде...

Сәгать алтыда Булатның эштән әти-әнисе кайтып җитәчәк. Нишләргә? Әлбәттә, өй эчен җәһәт кенә җыештырып, әүвәлге хәленә кайтарырга кирәк!





Рәссам Алла АЙСИНА

Өй эче ялт иткәнче, без тиз генә кайбер сорауларга җавап табып өлгерик әле...

1. Өй эчендә ничә бала бар?
2. Булатка дуслары нинди бүләкләр алып килгән?
3. Уйнаганда кайсы әйберләр ватылган?
4. Куркудан мәче кая качкан?
5. Ничә минуттан Булатның әти-әнисе кайтып җитәчәк?

Җавап: 1. Биш бала. 2. Машина, аю, китап, туп. 3. Ваза. 4. Палас эченә. 5. 10 минуттан (сәгать угы шулай күрсәтә).





Ипи, ипекәй...

Мин ипинең каян килгәнлеге турында күп уйлаганым булды. Үзем уйлап очына чыга алмагач, әнидән сорарга булдым. Әни: «Кызым, ипи җирдә үсә ул, аңа бик күп кешенең хезмәте кергән. Тракторчы җирне сөргән, чәчүче чәчкән, комбайнчы урган, машина йөртүче элеваторга илткән, тегерменче он тарткан, ипи пешерүче пешергән. Шулай кулдан-кулга күчә-күчә ипи безнең кибетләребезгә килеп җитә. Шуңа да ипи гомер-гомергә алтын бәһасына йөргән, кызым», – диде.

Әниемнең сүзләре күңелемә нык тәэсир итте.

Зилә МӨБАРӘКШИНА, 8 яшь.
Казан, 27 нче гимназия.

Иң кадерле ризык

Иртән мине тәмле ис уятты. Башка көннәрне урыннан торырга иренеп ятсам да, бүген аякларым үзләреннән-үзләре аш бүлмәсенә йөгерделәр. Күзем шунда ук өстәлгә төште. Анда парлары чыгып торган ап-ак ипи иде. Әнием иртән генә сауган сөт һәм кайнар икмәк белән чәй әзерләгән икән бит!

Мин тиз генә юындым да өстәл янына килеп утырдым. Күзем өстәлдәге тәмле кәнфитләрне дә, прәннекләрне дә, чәкчәкне дә күрмәде, бары тик кайнар икмәк белән генә эчтем мин чәйне. Мәктәпкә киткәндә әнием бер зур гына кисәкне сумкама да төреп салды. Юл буе шул

икмәк җылысы мине җылытып, мәктәпкә әйдәп барды.

Мин шундый нәтиҗәгә килдем: дөньяда нинди генә татлырак, тәмлерәк ризыклар булмасын, алар берсе дә ипине алыштыра алмый шул.

Ранилә ГЫЙЛЬМАНОВА, 10 яшь.
Әгерҗе, Кырынды

Икмәк булса – җыр да була

Хөрмәтле редакция! Без Татарстанның Мөслим районы Метрәй авылында яшибез, 2 нче сыйныфта укыйбыз. «Салават күпере» журналын көтеп алабыз һәм бик кызыксынып укыйбыз. Соңгы санда кайткан икмәк турындагы әкиятне укыдык-киңәшләштек тә, үзебез дә иншалар яздык.

Ипекәй үткән юл

Икмәктән олы нәрсә юк, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Ипекәйдән башка бер генә көн дә яши алмыйбыз. Ләкин ул ипине табынга куйганчы бик күп эшләргә кирәк шул. Минем бабам «КамАЗ» йөртә. Безнең абыйлар, бабайлар, без тук булсын дип, көнне төнгә ялгап эшлиләр: башта җирне сөрәләр, аннары бодай чәчәләр. Бодай үсеп өлгергәч, аны комбайн белән уралар һәм ындыр табагына ташыйлар. Басудан кайткан икмәкне чистартып, киптереп тегермәнгә он ясарга җибәрәләр. Әзер оннан бик күп төрле тәмле-тәмле ипи ризыклары пешерәләр.

Бер ипи пешерер өчен күпме кешенең хезмәте һәм сабырлыгы кирәк! Ә безгә, балаларга, ипекәйнең кадерен беләсе һәм зурларга рәхмәт әйтәсе генә кала.

Илнар ХАФИЗОВ.

Бодай, он, ипи...

Иң башта безнең басуларыбызга бодай чәчәләр. Шул бодай эре башаклы булып үсеп, өлгереп җитә. Аннан аны уралар, суктыралар, бөртеген тегермәндә тарттыралар, ипи пешерергә он ясыйлар. Шул оннан безнең әниләребез, әбиләребез күпереп торган тәмле ипи пешерәләр.

Минем дә әтием шул икмәкне үстерүгә үзенең тырыш хезмәтен кертә. Ул – игенче. Мин дә, үскәч, әтием кебек игенче булырга телим.

Рәмис ХӘЙРУЛЛИН.

Авыр, әмма мактаулы

Икмәк үстерү – җиңел эш түгел. Минем әтием һәм абыйларым – игенчеләр. Язын алар бодай, арпа, арыш чәчәләр, җәй буе игеннәрне тәрбияләп үстерәләр. Көз җиткәч, игеннәр өлгергәч, әтием һәм абыйларым комбайн белән уңышны җыеп алалар. Алар көне-төне эшләгәннән соң, ашлыкны чистартып, амбарларга салалар.

Менә нинди авыр, әмма мактаулы хезмәт икән ул – игенче булу!

Раил ШӘМСИЕВ.



Курыкмыйбыз суыктан

Ап-ак кыш җитте, –
Урамда салкын.
Куркытмый суык
Малайлар халкын.

Уйнаган чакта
Туңмый куллар да...
Тик нидер була
Итек, туннарга.

Чаңгы такмый да,
Шуарга була.
Тун да берүзе
Басып торала.

Айназ МӘННӘПОВ, 9 яшь.
Теләче, Олы Мишә.



Д. БУЛГАКОВА, 10 яшь.
Казан, 122 нче гимназия.

Бодай бөртеге

Беркөнне Илдар белән Марат урамда уйнап йөргәндә бер орлык тапты. Марат әйтте:

– Бу бит бодай бөртеге!

Илдар:

– Әйдә, без аны бакчага утыртыйк, – диде.

Малайлар бөртекне бакчага утырттылар, су сиптеләр. Берничә көннән бодай тишелде. Малайлар аны тәрбияләп үстерделәр: төбен йомшарттылар, ашладылар, су сиптеләр, чүпләрне утадылар. Бодайның башагы зур булды, саргайды. Сап-сары башакны малайлар беркөнне өзеп алдылар да, учларында уып бөртеген койдылар. Эре бөртекләрне ишек алдында йөргән әтәчкә бирделәр. Әтәч: «Кыт-кыт», – дип, тавыкларын чакырды һәм аларны бодай бөртекләре белән сыйлады. Тавыклар рәхәтләнеп ашадылар. Икенче көнне тавыклар, малайларга рәхмәт әйтеп, йомырка салып куйганнар иде.

Айдар ГАЛИМОВ, 8 яшь.
Мөслим, Метрәй.

Туган көн

Синең бүген
Туган көнең:
Җыелды бар
Якын кешең!
Синең алда –
Күп күчтәнәч;
Пеште мичтә
Ал пәрәмәч!
Синең бүген
Урын түрдә...
Үтте бу көн
Сизелми дә!

Ялкау песи

Тәрәз төбендә
Песи –
Алма бакчасын
Күзли.

Агачка кунды
Чыпчык.
Үчекли аны:
– Чык-чык!

Песи йөгереп
Чыкты...
...Ә чыпчык шундук
Очты.

Гөлия КАМАЛТДИНОВА,
11 яшь.
Казан, 129 нчы мәктәп.



Айгөл ХӨСӘЕНОВА, 7 яшь.
Чистай, Мөслим.

Йомшаккай

Минем Йомшаккай исемле песием бар. Ул ит, балык һәм эремчек ярата. Аны сыйпый башласаң, ул мырлый. Песи кәгазь кисәгенең селкенгәнен күрсә, аңа сикерә, уйный башлый. Йомшаккай бик шаян. Мин аны яратам.

Алсу ХАҖИЕВА, 11 яшь.
Азнакай, Балтач.

Бәхтияр ГЫЙЛЬФАН

Шәләй белән Вәләй

(Әкият кенә түгел)

Кичә-бүген заманда, сезнең-безнең авылда Шәләй һәм Вәләй исемле бер тинтәк белән бер мокыт яши иде.

Ятып аргач, чыктылар болар ишегалдына. Кыш. Буран. Шәләй юрган бөркәнгән, Вәләй матраска төренгән. Болар, үзара килешкәндәй, аякларының берсенә – киез ката, икенчесенә бәтинкә кигәннәр.

Ни гомер яшәп, моңарчы булмаган хәл: ишегалдын кардан чистартырга уйлады бу икәү. Шәләй кар көри башлады... сәнәк белән. Вәләй ишегалдын себермәкче була... канат белән. Мыштырдыйлар, матавыкланалар, мышкылдыйлар... Тик эшләре генә һич алга бармый...


Бер мәлне сәнәкне бер якка, канатны икенче якка аттылар да өйгә кире кереп яттылар...


Тинтәк белән мокытның җүнле эш майтарганнарын күргәнең бармы синең? Шул-шул! Карале, син дә алар кебек түгелдер бит?!




Фәрит МУЛЛАХМӘТ рәсеме

Әз-мәз мәзәк


1


4


3


2

1 Марат Рөстәмгә:
– Рөстәм, син мине туган көнеңә чакырасыңмы?
– Белмим әле.
– Ник?
– Чөнки миңа нәрсә бүләк итәсеңне белмим.

2 Ике малай сөйләшә:
– Кайсыбер этләр хуҗаларыннан да акыллырак булалар.
– Каян беләсең? Булмас!
– Булмас сиңа! Минем үземнең этем шундый.

3 – Синең песиең бигрәк әйбәт. Бездә тычканнар күп, песиеңне бер көнгә миңа биреп тор әле.
– Юк инде, тычканнарыңны безгә алып кил...

4 – Бүген аквариумга яңа су салдыңмы?
– Нигә? Кичәге суны да эчеп бетермәгәннәр бит әле!

Мәзәкләрне Г.ЯРМИЕВА туплады.

Салават күпере

2(203) — 2007

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Ф.МУЛЛАХМӘТ рәсеме.

Тышлыкның беренче битендә Ринат МӘННАН шигыре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: *salavatkupere@mail.ru*

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тасларга бүленде.


«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 15.02.2007 ел.
Басарга кул куелды 15.02.2007 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 12382 данә. Заказ С-174.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова, А.Вакказов.

Бөясе килешү буенча
Индекс 73953



Ләбиб ЛЕРОН

Кызык кыш

Кыш беткәндә... кыш килде –
Быел кыш кызык итте...
Кар яудыра-яудыра,
Кыш тәмам кызып китте!

Башта билдән булган көрт
Мине дә узып китте;
Койманы һәм мунчаны...
Өйне дә узып китте!

...Ярый әле кышның, дим,
Үзен яз кызык итте:
Кояш булып чыкты да
Бөтен карны эретте.